# Әмирхан Еники- әдипләр остазы ...



# Әмирхан Еникинең тормыш юлы.

- Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникиев 1909 елның 17 февралендә( яңа стиль белән 2 мартта)Элеке Уфа губернасы Бәләбәй өязе ( хәзерге Башкортстанның Благовор районы) Яңа Каргалы авылында таза хәлле крестьян гаиләсендә туган.1911елда анын әтисе гаиләсе белән Яңа Каргалыдан кырык чакрым ераклыктагы Дәүләкән дигән авылга күченә. Әмирханның балалык һәм мәктәп еллары шул авылда уза.

# Күренекле әдип –прозаик Әмирхан Еники.




- Иҗат эше минем өчен башта ук шәхси эш, өзлексез уйлану белән бәйләнгән күңел һәм намус эше иде.Мин бары үзем белгәнне, үзем ышанганны гына язырга тиеш дип уйлыйм.
- Ә.Еники

# Еники-психологик язучы.

- Әлбәттә, Әмирхан Еники иҗатының ахырына кадәр конъюктурага якын да килмәгән кеше. Гомумән, татар зыялыларының, татар мәгърифәтчеләренең традицияләрен дәвам итергә омтыла. Гасырлар арасында күпер салу, рухи кыйммәтләрне саклау өчен тырышкан.

  Рәмзил Вәли



# Татлы аһәңнәр...

- Мәхәббәт бит ул – мөкатдәс бит ул, олы бәхет бит ул. Шуңа күрә мәхәббәт белән шаярырга ярамый чөнки- ул вөҗдан, намус бурычы.




Әмирхан Еники һәм Нәҗия ханым *(сөйкемле песиләре Аппак белән).* *1998 ел.*

# Серле йолдызлык.

- Язучы һәрвакыт матурлыкка сусап, матурлыкны сагынып яшәргә тиеш... Гыйбрәт алыр, Күңелне баетыр, теләкләрне үстерер өчен генә түгел,һәр төрле түбәнлек- ваклыклар белән килешмәс өчен,шуларга нәфрәт саклар өчен дә кирәк бу...
- Әмирхан Еники.

# Әмирхан – матур сүз остасы.

- Әмирхан Еники – минем өчен тере классик, матур сүз остасы. Әйтер идем :ул- пороза белән яза торган шагыйрь.Аның әсәрләре – кеше йөрәгенә ята торган әсәрләр.Аңа ул табигате белән нечкә күңелле, кешелекле булуы белән ирешә.Шул яклап ул – миңа өлкән дус та, остаз да.

Нажар Нәжми.

# Ә.Еникинең танылган әсәрләре

Тормыш күренешләрен һәм кеше характерларын анализлауда психологик тирәнлеккә омтылу илленче-җитмешенче еллар арасында әдипкә тагы да зуррак иҗади уңышлар алып килә. Язучының «Рәхмәт, иптәшләр!» (1951—1952), «Саз чәчәге» (1955), «Йөрәк сере» (1957), «Рәшә» (1962), «Вөждан» (1968), «Без дә солдатлар идек» (1971), «Гөләндәм туташ хатирәсе» (1975) исемле повестьларыЯлгызлык» (1957), «Туган туфрак» (1959), «Матурлык» (1964), «Төнге тамчылар» (1964), «Коръән хафиз» (1964), «Әйтелмәгән васыять» (1965), «Курай» (1970), «Тынычлану» (1978) кебек хикәяләре, кешеләр арасындагы төрле катлаулы мөнәсәбәтләрне реалистик рухта яктыртуы һәм заманны борчыган әхлакый-этик проблемаларны кыю рәвештә күтәрүе белән бергә, сәнгатьчә камил эшләнүләре җәһәтеннән дә аерым игътибарга лаеклар. Геройның күңел серләренә тирән үтеп керә белү осталыгы, фикернең фәлсәфи үткенлеге һәм драматик киеренкелеге, форманың пөхтә һәм җентекле эшләнүе, тел-сурәтләү чараларының төрле стилистик буяуларга, образлы фикерләүдәге милли үзенчәлекләргә бай булуы — болар Ә. Еники талантының төп сыйфатларын тәшкил итәләр.

# Әмирхан ага яшәгән йорт.

*Әмирхан Еники эзеннән шәһәр буйлап без дә сәяхәт итәргә уйладык. Әмма 30–40 ел узганнан соң. Ярты гасыр эчендә Казан, әлбәттә, танымаслык булып үзгәрде, матурайды, чистарды. Ә тарихи биналар язмышы язучы сөйләгән заманга караганда да мөшкелрәк. Ул телгә алган биналарның күбесеннән коры калдык, тарихилыкны исә тагын да күбрәк югалттык.*



# Әдипнең бүләкләре.

Ә. Еникинең әдәби иҗаты Совет хөкүмәте тарафыннан югары бәяләнде. Ул Хезмәт Кызыл Байрагы (1979) һәм «Почет Билгесе» (1957) орденнары белән бүләкләнде. 1984 елда аңа «Юлчы» исеме белән чыккан хикәяләр җыентыгы һәм русча тәрҗемәдә басылган «Повести и рассказы» (1982) китабы өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.
Ә. Еники —1946 елдан СССР Язучылар союзы члены иде.

Әмирхан Еники 2000 елның 16 февралендә Казан шәһәрендә вафат булган.